СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_26_» ___май___ 2022 ел** **№ _143_**

**Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе рәисе И.Г. Нуриев мәгълүматын тыңлап, Арча район Советына конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураларны карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 37 статьясына, «Җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына, Арча муниципаль районы Уставына таянып, Арча муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе итеп Гатиятов Ренат Мансур улын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә Арча муниципаль районы башлыгының айлык акчалата түләвенең 60% нан да ким булмаган күләмдә айлык акчалата түләү билгеләргә.
3. Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриевка Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе белән 2022 елның 30 маеннан контракт төзергә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев